МБГБУ “Балтач гимназиясе”нең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Әхмәтова Рәйсә Шамиловна.

Мастер-класс: “Креатив булыйк ”.

Максат: Дәреснең ориентлаштыру-мотивлаштыру этабында кулланыла торган алымнар белән таныштыру.

Бурычлар: 1. Креативлык турында белешмә бирү.

2.Һәр алымга аңлатма бирү.

3.Һәр алымның биремен үтәү һәм нәтиҗә ясау.

Исәнләшү.

I. Кемнең кесәсендә 10 тиен акча бар?

Эх, менә бу кәрзиндәге бөтен әйбер аныкы булыр иде.

Кәрзиндәге әйберләрне карау . (1 нче парта 3 нче рәттәге кеше) Кәрзиндә бәрәңге 15-20 данә, лимон-2данә., суган-10д., йомырка-3д., мәрсин балыгы- 90 гр., тавык-225гр.

Боларны 10 тиенгә алып булыр дип ышанасызмы?

Шкатулкада нәрсә икәнен карау. (1 нче парта 2 нче рәттәге кеше) Кәгазьдән ясалган 1908 нче елгы акчалар күрсәтү.

Кайсы чор бу, кем акчасы? ( 1908 ел, Николай 2) Ә хәзер 10 тиенгә нәрсә тия икән? Лимон ничә сум? Суган,бәрәңге? Алайса, менә бу 1 конфет?

3 төркем. 1 данә конфет бәясен белә. 1кг- 218, 90 сум.(2 төркемгә үлчәү, 1сенә бәясе язылган 10 конфетлы пакет) 3 минутка

Ә кәрзин һәм шкатулка турында нинди фикерләр бар? серне ачам: Тукай.

Габдулла Тукайның юл кәрзине

Габдулла Тукай Газизә апасына бүләк иткән тартмачык.

Ә тиеннәрнең Тукайга ни катнашы бар икән?

Язылган һәр шигырь юлы өчен Габдулла Тукайга 50 тиен көмеш яисә алтын белән түли торган булганнар. Үз заманында ул иң күп түләнүчән шагыйрь булган.

4 юлы өчен 2 сум алган, мондый 20 кәрзин дигән сүз.

НӘТИҖӘ. Димәк, без бүген кем турында сөйләшәбез икән, Аның турында күп белгән кебек тоелса да, өйрәнәселәре дә калган икән. Бүген Тукай турында өйрәнәбез дип тиз генә әйттермичә, туры юлдан түгел, ә урап килү отышлырак, минемчә.

II. Мин сезгә мотивлаштыруның 1 алымын күрсәттем.

Дәрес башындагы 5 минутта укучыларны гаҗәпләндерергә кирәк. Шуны да истә тотарга: мине шаккаттырган әйбер генә (ансы да әле гел түгел) балаларны гаҗәпләндерергә мөмкин. Укучы өчен нинди булса да яңалык булырга тиеш. Бөтен әйберне белеп, тиз генә җавап табып барса, шулай ук бик яхшы түгел бит. Үзеңне гаҗәпләндергән әйберне “бик тәмләп” тәкъдим итсәң, аппетит белән ашалган ризык кебек әйбәт сеңәчәк. Бу укытучыдан иҗади осталык, мөгаллимнең үз эшчәнлек стилен таләп итә. Кыскасы, креативлылык сорала. Нәрсәне аңлата соң ул?

Креативлык – гадәти тормышта традицион схемаларга хас булмаган яңа идеяләрне уйлап табу, тормышка ашыру юлында ярдәм итүче иҗади сәләт. Ә креатив фикер йөртү –стандарт булган хәл-вакыйгалардан стандарт булмаган чишелешләр табу, юмор хисе, баш миен тиз вакыт аралыгында башкача уйларга мәҗбүр итү. Бу очракта кызык булмаган, тапталган идеяләр, фикерләр читтә кала, әйберләргә беренчел караш юкка чыга, кешегә төрле эшчәнлек өлкәсендә зур мөмкинлекләр ачыла. Креативлык белем бирүдә укучы һәм укытучы арасында иҗади хезмәттәшлек , белем алуга уңай омтылыш булдыра. Бүген фән-техника бик тиз үсә, шуңа балалар алдында торган бурычлар да катлаулана. Алга китеш һәм үсеш булсын өчен, кешеләр креативлыкка мохтаж. Иҗади кешеләр яки аерым төркемнәрнең креативлыгы аркасында, тормышыбыз көннән-көн камилләшә, яңалыклар барлыкка килә. Креатив фикер йөртү технологиясенең **актуальлеге** җәмгыятьнең бүгенге чыгарылыш сыйныф укучылары алдына зур таләпләр куюы белән дә аңлатыла.

Педагогика өлкәсендә Зайцева М.В. , Степанюк, И. В. ,Печенежская В.Н., Утёмов В.В. һәм Зиновкинаның саллы гына хезмәтләре бар. Алымнар бик күп һәм төрле. Әмма аларны үз фәнеңә туры китерерлек итеп җайлаштырырга кирәк. Мәсәлән,

1.Темага күпмедер кагылышлы проблемалы сорау бирү.

2.Уйландырырлык видео күрсәтү.

3. Дәрескә бөтенләй туры килмәгән предметлар белән эшләү һәм башкалар.

III. Дәрес башында, җиңел эшләр башкарып, уңыш ситуациясен булдыру да әйбәт, минемчә. Моңа тагын 1 алым. Монсы проектка мотивлаштыру да була ала.

Хәзер партадагы мисалларны чишик . Мисаллар эшлиләр.

400+300= ... см = ...м

7х100= … см= … м

800-100= ... см=... м

1400:2= ...  см= ...м

400+300= ...  см = ...м

Ничә чыкты?  Бөтенесенең җавабы 7 була.

7 саны турында нәрсәләр әйтә аласыз?  Җаваплар

Мисалны табышмакка алмаштырабыз. Бу сан белән табышмак.

Җиде төрлесен беләм,

Икесен бик яратам,

Ләкин сезгә әйтмимен,

Әйтсәм, серен югалтам,

Кем белә, әйдә, әйтсен!  Җаваплар

Җаваплар белән килешәм, әмма миңа кирәге булмады. Мин көткән җавап парталардагы киндер савыты эчендә. Тапкан кеше ала. Нәрсә икән?  Җиләк була.

Җавапны күз белән шигырьдән дә эзлибез.

Тагын бер кат табышмакны укыйбыз. Монда җиләк кайда соң?

Акрошигырь турында әйтелә. Һәр юл башындагы беренче хәрефләренннән җавап чыга торган шигырь-табышмак.

Андый шигырьләр язучы Мөҗәһит  Әхмәтҗанов белән таныштыру.

Нәтиҗә. Бу алымны дәрес темасына да бәйләргә кирәк бит әле. Мисал өчен АЛМАШЛЫК, ФИГЫЛЬ 7 төркемчә.  Җ хәрефе, ЕЛ ФАСЫЛЛАРЫ темалары.

Бу алым үзеңә, гаиләгә, класска, укытучыларга акрошигырьләр язып, проект эшләргә этәргеч. Проект эшләрен күрсәтү.

3.  Ә Тукай безгә нәрсә калдырган?  (Туган телне)

Сезнеңчә, татар теле Америка университетында укытыламы?  ҖАВАПЛАР.

Бу сорауга Күренекле якташыбыз Әхмәт Мазһаров җавап бирер. Академик , Техник фәннәр докторы , профессор , ТРның атказанган химигы  Ә.М. Мазһаров – дөньяда нефтьне меркаптаннан чистарту процессын беренче уйлап табучы. Аның технологияләре буенча 40тан артык җайланма төзелә, шуларның икесе – Болгариядә, өчесе – Иранда …

Игътибарыгызга видео,  аны караганда, башыгызга килгән 1 сорауны партадагы битләргә язып куярсыз. (Видеода Мазһаров кызының Америка университетында татар теле укытуын сөйли).

Укучыларда туарга мөмкин сораулар (Кем соң бу ваще? Нәрсәгә соң ул Америкада татар теле? )

Бу сораулар, гадәттә , өй эшенә бирелә һәм алар икенче дәреснең башында карала.

Нәтиҗә. Милли компонент. Туган ягыңның күренекле татарлары белән горурлану.ТАТАР ТЕЛЕНӘ МӨНӘСӘБӘТНЕ ҮЗГӘРТҮ.

Кемнәрдер Видеолар табып миңа салалар. Әкренләп үзләре дә видео төшерәләр.

РЕФЛЕКСИЯ. 3 алым күрсәтелде.Миңа сезнең фикер бик кадерле.

Кызыксындыру өчен, Сез бу алымнарның кайсын кулланыр идегез? Битләргә сан (1,2,3) белән генә язып куегыз.

Рәхмәт сезгә,хезмәттәшләр,

Мине тыңлаган өчен,

Тырышып эшләгән өчен,

Креатив булган өчен!!!